**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ ВЕРХНЕ-ЧЕРШИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**ул. Ленина, дом 29а. с. Верхние Чершилы, 423364 телефон (85559) 4-21-41**

ОКПО: 93068462 ОГРН:103160400100
ИНН: 1636001964 КПП: 163601001

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЮГАРЫ ЧЫРШЫЛЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**Югары Чыршылы авылы, Ленин урамы, 29а йорты, 423364, телефон (85559) 4-21-41**

ОКПО: 93068462 ОГРН: 103160400100
ИНН: 1636001964 КПП: 163601001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**20.11.2018 ел** **№ 21**

Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл жирлеге
Советының 2014 нче елның
10 нчы ноябрендәге 14нче санлы
«Физик затлар милкенә салым
турында» карарына үзгәрешләр
кертү турында

«Россия Федерациясендә жирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлеше 2 пункты, «Россия Федерациясе Салым кодексының 52 статьясына беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 августындагы 334 - ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Салым кодексының 56, 399 статьяләренә нигезләнеп, Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл жирлеге Советы карар итте:

1.Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл жирлеге Советының 14.11.2014 ел, 14нче санлы «Физик затлар милкенә салым турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.2.1. подпунктына «фатирлар» сүзеннән соң «фатир өлешләре» сүзләрен өстәргә.

2) 2.3.1. подпунктына «торак йортлар» сүзләреннән соң «торак йортларның өлешләре» сүзләрен өстәргә.

3) 3нче пунктка түбәндәге эчтәлектәге 3.1нче подпункт өстәргә:

«3.1. Ел башына унсигез яше тулмаган өч һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләнең, шул исәптән үги балалары, опека һәм попечительлеккә алынган балалары булган күп балалы гаиләнең, ата-ананың икесенең берсенә салым салынучы бер объектына (сайлап алып) физик затлар милкенә салымның түбәнәйтелгән ставкасы рәвешендә салым ташламасын билгеләргә:

| Объект төре | Гамәлдәге ставка | Ташламалы ставка |
|---|---|---|
| Шәхси торак йорт яки торак йортның бер өлеше | 0,3 | 0,15 |

| | | |
|---|---|---|
| Күпфатирлы йортта торак бина (фатир, фатирның бер өлеше, бүлмә) | 0,2 | 0,1 |

Салым ташламасына хокукны раслаучы документлар салым түләүчеләр - физик затлар тарафыннан салым салу объекты булган мөлкәт урнашкан урындагы салым органнарына, үткән салым чорыннан соң килүче елның 1нче февраленнән дә соңга калмыйча, тапшырыла.».

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә, шулай ук мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3.Әлеге карар 2019нчы елның 1нче гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин халыкка игълан ителгән көннән соң бер айдан да иртәрәк түгел.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге Советы Рәисе И.Н.Камалетдинов